Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаятенә бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2021 елның 21 декабре

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешенең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Т.Ә. Вәлиев шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Ф.Р. Волкова мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актны чыгарган орган вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге баш киңәшчесе Э.А. Даутова, суд утырышына чакырылган вәкилләр — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты вәкиле — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Торак сәясәте идарәсе юридик бүлеге башлыгы Р.Н. Сафин һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе вәкиле — «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесенең торак сәясәте бүлеге башлыгы Г.Р. Абдулманова аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Т.Ә. Вәлиев «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) 8 статьясындагы 8 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Шикаять биргән вакытта аталган норматив хокукый нигезләмә граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле орган билгеләнгән тәртиптә бирелгән номер, чиратлылык турында белешмә бирергә тиешлеген күз алдында тоткан.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче үзенең хатыны, кызы һәм аның балигъ булмаган өч баласы белән гомуми мәйданы 26,05 кв. м булган тулай торак бүлмәсендә теркәлгән. Аның аз керемле дип танылган гаиләсе торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ буларак 2010 елның 19 февраленнән исәптә торган. Торак урыны алуга үз чиратын ачыклау максаты белән гражданин Т.Ә. Вәлиев Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә мөрәҗәгать иткән, алар аңа Казан шәһәренең Идел буе районы буенча чиратлылык турында мәгълүмат биргәннәр. Шуның белән, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, аны ялгыштырганнар, чөнки Россия Федерациясе торак законнары нигезләмәләре буенча социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары аз керемле гражданнарга муниципаль торак фондыннан чиратлылык тәртибендә, мондый гражданнарны исәпкә алу вакытыннан чыгып бирелә һәм шуңа күрә Казан шәһәре районнарындагы чиратлылык әһәмияткә ия түгел. Шуңа бәйле рәвештә гражданин Т.Ә. Вәлиев тиешле мәгълүматларның граждан исәпкә алынган район буенча түгел, ә Казан шәһәре буенча бердәм чиратлылыктан чыгып бирелергә тиеш булуын күрсәтә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, Казан шәһәренә карата дәгъва белдерелә торган нормада гражданга чиратлылык турында нинди мәгълүматлар бирелергә тиешлеге — шәһәр яки район буенча булуы ачык билгеләнергә тиеш. Моннан тыш, ул билгеләп үткәнчә, карала торган нигезләмә эчтәлегеннән гражданга номер, чиратлылык турында белешмәләр нинди тәртип нигезендә бирелергә тиешлеге аңлашылмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче үзенең конституциячел хокуклары бозылган дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга

торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче өлеш), 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; һәркем торакка хокуклы; беркем дә торагыннан нигезсез рәвештә мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

Эшне суд утырышында карый башлаганда «“Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына һәм “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 22 июнендәге 41-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән шикаять белдерелә торган нигезләмәгә бирелгән номер, чиратлылык турында граждан үтенечнамәсе буенча белешмәләр бирү тәртибе вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнүен төгәлләштерүче үзгәреш кертелгән. Шуның белән бергә, бу Татарстан Республикасы Конституция судына 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен гамәлдәге редакциясендә карауга комачауламый, чөнки тулаем алганда аның хокукый эчтәлеге һәм хокук куллану практикасында мәгънәсе үзгәрешләр кичермәгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган

актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алынган гражданнарга үзләренең чиратлары турында белешмәләр алу хокукын гамәлгә ашыру өчен хокукый нигез булып торган дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Нигезләмәсенә карата гражданин Т.Ә. Вәлиев тарафыннан шикаять белдерелә торган «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә элегрәк Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде, ул, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Россия Федерациясенең һәм аның субъектларының социаль яклау һәм торак законнары өлкәсендә Россия Федерациясе Конституциясендә билгеләнгән эшләр бүлешүдән чыгып эш иткән һәм федераль законнар һәм Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтен дөрес гамәлгә ашырган

дигән нәтиҗәгә килде (2013 елның 18 октябрендәге 55-П номерлы, 2020 елның 16 июнендәге 91-П номерлы карарлар). Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карарлары һәм аларда чагылдырылган хокукый позицияләр үз көчләрен саклый.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемнең торакка хокукын беркетә; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья). Мәгънәсе буенча тиңдәш гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 һәм 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Әлеге конституциячел нормалар 1948 елның 10 декабрендәге Кеше хокуклары гомум декларациясенең 25 статьясы һәм 1966 елның 16 декабрендәге Икътисадый, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы нигезләмәләренә тәңгәл килә, алар, лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак, һәркемнең торакка хокукын таныйлар.

Россия Федерациясе Торак кодексының 2 статьясы нигезендә дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары гражданнарның торакка хокукларын гамәлгә ашыру өчен үз вәкаләтләре чикләрендә шартлар тәэмин итәләр, шул исәптән дәүләт яисә муниципаль торак фондыннан социаль яллау шартнамәләре яки торак урыннарны яллау шартнамәләре буенча гражданнарга билгеләнгән тәртиптә торак урыннар бирәләр (3 пункт).

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча үз вәкаләтләре чикләрендә карарлар кабул итеп, шактый дискрециягә ия, әмма ул тигезлек, гаделлек һәм ярашканлык конституциячел принциплары белән, хокукый җайга салуның билгелелек таләпләре белән, шул исәптән ул тудыра торган хокукый нәтиҗәләрдә дә чикләнгән.

Гражданин Т.Ә. Вәлиев тарафыннан шикаять белдерелә торган 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше

нигезендә социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны бирүгә аның чираты турында граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле органның үзе билгеләгән тәртиптә белешмә бирү бурычы беркетелгән.

Әлеге нигезләмә гамәлдәге хокукый җайга салу системасында үзенең норматив-хокукый эчтәлеге буенча социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру механизмының бер өлеше булып тора, аның хокукый нигезен Россия Федерациясе Торак кодексының китерелгән конституциячел күрсәтмәләре һәм нормалары тәшкил итә. Аерым алганда, әлеге Кодексның 49, 51, 52 статьялары нигезләмәләре буенча аталган механизм социаль наем шартнамәсе буенча җирле үзидарә органы тарафыннан аз керемлеләр һәм торак урыннарына мохтаҗ дип танылган гражданнарга муниципаль торак фондыннан торак урыны бирүне күздә тота, шулай ук торак урыннары бирү максатларында яшәү урыны буенча җирле үзидарә органы тарафыннан аларны исәпкә алу процедурасын үз эченә ала. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 49 һәм 57 статьялары нигезендә күрсәтелгән торак урыннары гражданнарга муниципаль торак фондыннан чиратлылык тәртибендә аларны җирле үзидарә органнарында исәпкә алу вакытыннан чыгып бирелә. Әлеге Кодексның 14 һәм 19 статьялары нигезендә, муниципаль берәмлекләргә милек хокукындагы торак урыннар бергәлеге буларак, мондый торак фондына карата бүлү функцияләрен җирле үзидарә органнары гамәлгә ашыра.

Шулай итеп, югарыда аталган норматив хокукый күрсәтмәләрнең эчтәлегеннән күренгәнчә, социаль наем шартнамәсе буенча торак урыннары алуга гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыру механизмын тәэмин итү нигезендә чиратлылыкны саклау принцибы ята.

Китерелгән федераль нормалар нигезендә республика закон чыгаручысы үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләр кысаларында 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан аларга торак урыннары бирү тәртибен, шулай ук социаль наем шартнамәләре буенча

муниципаль торак фондыннан бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару тәртибен регламентлаган. Күрсәтелгән Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 8 статьяларының үзара бәйле нигезләмәләреннән чыгып, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу алар тарафыннан яшәү урыны буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органына тапшырылган гражданнар гаризалары нигезендә гамәлгә ашырыла, әлеге орган, үз чиратында, гражданнарны тиешле исәпкә алу (исәпкә алудан баш тарту) турында карар кабул итә. Карала торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 5 статьясы белән үзара бәйләнештә Казан шәһәре Башкарма комитеты вәкаләтле орган булып тора, аның структурасына территориаль органнар, аерым алганда, Казан шәһәренең Авиатөзелеш һәм Яңа Савин, Вахитов һәм Идел буе, Киров һәм Мәскәү, Совет районнары администрацияләре керә.

Шикаять белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 6 өлеше нигезендә торак урыннарына мохтаҗ буларак исәпкә алынган һәр гражданга вәкаләтле орган тарафыннан кирәкле документлар кертелгән исәпкә алу эше ачыла. Шул ук вакытта мондый гражданнар тарафыннан социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алу чиратлылыгы алар тарафыннан гариза бирү вакыты буенча билгеләнә.

Карала торган Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезләмәләрен үстереп, «"Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында" 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру өчен кирәкле документларның формаларын раслау хакында» 2008 елның 31 гыйнварындагы 57 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты исәпкә алу эшен алып бару тәртибен (алга

таба — Тәртип) раслаган. Тәртип нигезендә социаль наем шартнамәсе буенча бирелә торган торак урынына мохтаҗ буларак исәпкә алынган һәр гражданга аны исәпкә алу өчен нигез булырлык кирәкле документлар кертелгән исәпкә алу эше ачыла; вәкаләтле орган карары буенча исәпкә алу эше социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару өчен җаваплылык йөкләнгән вазыйфаи зат тарафыннан алып барыла; исәпкә алу эшенә Социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу кенәгәсендәге номерга туры килә торган тиешле номер бирелә; исәпкә алу эшендәге документлар алыну даталары буенча хронологик тәртиптә урнаштырыла, астан өскә таба, номер куела һәм алынуы буенча исемлеккә кертелә бара.

Шулай итеп, вәкаләтле орган, закон нигезендә үзенә беркетелгән вәкаләтләр кысаларында, гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар дип тану, аларны тиешле исәпкә кую һәм, димәк, мондый гражданнарның чиратлылык исемлеген алып бару механизмы эшен тәэмин итәргә тиеш.

Тәртипнең китерелгән нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә Татарстан Республикасы Законының шикаять белдерелә торган нормасын анализлау күрсәткәнчә, ул үзенең табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча гражданның социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү хокукын гамәлгә ашыруның реаль ихтималлыгын аңа алдан күрергә мөмкинлек бирә торган — исәпкә алу вакытыннан чыгып, муниципаль берәмлектә торак урыннары бирүгә чиратлылыкның гомуми исемлегендә үзенең чираты буенча нинди урында торуы турында белешмәләр алу хокукын тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Карала торган хокукый җайга салудан аңлашылганча, вәкаләтле органга гражданнарга аларның чиратлылыгы турында белешмәләр бирү буенча беркетелгән бурыч вәкаләтле орган — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм аның территориаль органнары тулаем муниципаль берәмлек буенча гражданнарның чиратлылыгы турында бердәм мәгълүматларга ия булырга тиешлеген күздә тота.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы

Конституция суды түбәндәге нәтиҗәгә килә: гамәлдәге хокукый җайга салу системасында муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру механизмының элементы булып торучы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше үзенең конституциячел-хокукый мәгънәсе буенча граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле органның чиратлылык турында үзе билгеләгән тәртиптә белешмә бирү бурычын күз алдында тота, алар, исәпкә алу вакытыннан чыгып, муниципаль берәмлектә торак урыннары бирүгә чиратлылыкның гомуми исемлегендә үзенең чираты буенча кайда булуы турында күрсәтелгән хокукны гамәлгә ашыруның реаль мөмкинлеген чагылдырыр иде.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норма үзеннән-үзе хокук куллану практикасында аны әлеге закондагы җайга салу белән ярашмый торган башкача аңлату мөмкинлегенә юл куймый һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу — шәһәр эчендәге районнар администрацияләре тарафыннан, ә торак бүлеп бирү башкарма комитетлар тарафыннан гамәлгә ашырылган муниципаль берәмлекләрдә гражданга үзенең чиратлылыгы турында бары тик үзе исәпкә алынган район буенча гына белешмәләр бирелә дип куллануны кире кага.

Дәгъва белдерелә торган норманы башкача аңлау һәм куллану социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алуга гражданнарның хокукларын тәэмин итүнең конституциячел әһәмиятле максатлары белән туры килмәслек һәм нигезсез булыр иде һәм аның чиратлылыгы турында граждан үтенечнамәсе буенча вәкаләтле органның белешмә бирү бурычы, һәм, димәк, аның торак урыны алуга хокукының кайчан гамәлгә ашырылачагын алдан күрү мөмкинлеген чынлыкта гамәлдә булган һәм нәтиҗәле итүгә түгел, ә декларатив һәм иллюзор характерда булуына китерер иде.

Шуның белән бергә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный.

Эшне тыңлауга әзерләү чорында Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетыннан алынган мәгълүматтан һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе» муниципаль казна учреждениесе вәкилләренең аңлатмаларыннан күренгәнчә, 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен үтәү йөзеннән расланган вәкаләтле орган тарафыннан граждан үтенечнамәсе буенча шул исәптән аның муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү чиратлылыгы турында белешмәләр бирү тәртибе юк. Карала торган Законның 8 статьясындагы дәгъва белдерелә торган 8 өлешендә каралган вәкаләтле органның граждан үтенечнамәсе буенча үзе билгеләгән тәртиптә аның чиратлылыгы турында белешмәләрне бирергә тиешлеге гражданнарның торак шартларын яхшыртуга хокукын гамәлгә ашыру механизмының аерылгысыз элементы булу фактын исәпкә алып, мондый мәгълүмат бирү тәртибе ачык, төгәл, ике төрле аңларга урын калмаслык итеп бәян ителгән бердәм хокукый һәм процедура кагыйдәләренә нигезләнгән булырга тиеш.

Хокук куллану практикасында барлыкка килгән дәгъва белдерелә торган норманы интерпретацияләү вариантларын анализлау фактта вәкаләтле орган тарафыннан гражданга үзенең чиратлылыгы турында белешмә бирү бурычын үтәү процедурасына төрлечә якын килү мөмкинлеге турында сөйли. Бу гражданның, ахыр чиктә, бары тик үзе исәпкә алынган Казан шәһәре районы буенча чиратлылыгы турында гына мәгълүмат алуына китерә. Бәян ителгәннәр республика закон чыгаручысының хакыйкый ихтыярын үзгәртү һәм гражданнарның хокукларын бозу турында нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды карала торган нигезләмәне бертөрле куллану максатларында Казан шәһәрендә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗ

гражданнарны исәпкә кую тәртибен регламентлый торган муниципаль хокукый җайга салу граждан үтенечнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү чиратлылыгы турында Казан шәһәре районнары администрацияләре тарафыннан белешмәләр биргәндә кулланылырга тиешле норматив материалны төгәлләштерү өлешендә камилләштерүне таләп итә дип саный.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлеше нигезләмәсе, аның дәлилләренә карамастан, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәдә аның социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль торак фондыннан торак урыны алу хокукын чикләми һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дигән нәтиҗә ясый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясындагы 8 өлешен, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән

үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

3. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 102-П**

**Татарстан Республикасы Конституция суды**